81.632.3я2
Т41
БА-393888



АДЛЕР ТИМЕРГАЛИН

# РУСЧА-ТАТАРЧА АСТРОНОМИЯ ТЕРМИННАРЫ СҮЗЛЕГЕ

•

# РУССКО-ТАТАРСКИЙ СЛОВАРЬ АСТРОНОМИЧЕСКИХ ТЕРМИНОВ



ТАТАРСТАН КИТАП НӘШРИЯТЫ
ТАТАРСКОЕ КНИЖНОЕ ИЗДАТЕЛЬСТВО

АДЛЕР ТИМЕРГАЛИН

# РУСЧА-ТАТАРЧА АСТРОНОМИЯ ТЕРМИННАРЫ СҮЗЛЕГЕ

•

# РУССКО-ТАТАРСКИЙ СЛОВАРЬ АСТРОНОМИЧЕСКИХ ТЕРМИНОВ

## АҢЛАТМАЛЫ СҮЗЛЕК

## ТОЛКОВЫЙ СЛОВАРЬ

Татарстан китап нәшрияты
Татарское книжное издательство
2021

Государственное бюджетное
учреждение культуры
«Оренбургская областная универсальная
научная библиотека им. Н.К. Крупской»

БД-393888

С400

# А

***Аберрации оптических систем** – Оптик системаларның аберрациясе.* Оптик системалар биргән сурәттәге ялгышлар һәм кимчелекләрнең бер төре. Астрономия инструментларында бу кимчелек мөмкин кадәр азрак булырга тиеш.

***Аберрация** – Аберрация.* Латинча (нәрсәдән дә булса) «тайпылыш» дигән мәгънәдәге сүздән. Астрономиядә, яктылык чыганагы белән алгыч җайланмасы бер-берсенә карата хәрәкәт иткәндә, яктылык нуры юнәлешенең үзгәрүе аркасында килеп чыга. Нәтиҗәдә күк сферасындагы яктырткыч, читкәрәк тайпылып, чак кына күченгән сыман булып күренә.

***Аберрация вековая** – (Күп)гасырлык аберрация.* Гасырлык аберрация Кояш системасының Галактика үзәге тирәсендә хәрәкәт итү эффектын исәпкә ала.

***Аберрация годичная** – Еллык аберрация.* Мондый аберрация Җирнең Кояш тирәсендәге еллык хәрәкәтен исәпкә ала. Еллык аберрация яктырткычны Җирнең Кояш тирәли хәрәкәтендәге моменталь апекска таба тайпылдырып күрсәтә, шуның аркасында йолдыз күк йөзендә кечерәк кенә эллипс сызгандай була.

***Аберрация дифракционная** – Дифракцион аберрация.* Фотообъектив диафрагмасында һәм кысасында барлыкка килеп, фотообъективның үткерлек сәләтен чикли торган кимчелек.

*Дифракция* латинча «сынган», «сынык» мәгънәсендәге сүздән.

***Аберрация монохроматическая** – Бер төс аберрациясе, монохроматик аберрация.*

Кара: ***Аберрация объектива.***

***Аберрация объектива** – Объективның аберрациясе.* Оптик җайланмадагы (электрон-микроскоптагы, фотоаппараттагы һ. б.дагы) объектив идеаль сыйфатка ия булмаганлыктан, сурәтнең төгәлсезлеге яки берәр төстә булып күренүе һ. б. Гомумән, һәрбер объективка яки окулярга теге яки бу дәрәҗәдә аберрация кимчелеге хас.

***Аберрация суточная** – Тәүлеклек аберрация.* Мондый аберрация Җирнең үз күчәре тирәсендә әйләнүе аркасында килеп чыга.

***Аберрация сферическая** – Сферик аберрация.* Сферик элементлардан гына төзелгән барлык объективларга да хас кимчелек. Сферик аберрация аркасында линзаның кырый өлешләре аша үтә торган нурлар линзаның үзәгенә якынрак узган нурларга караганда линзага якынрак ноктада кисешәләр. Фокус ноктасының буй күчәр буйлап күчеше *сферик буй аберрация* дип атала.

***Аберрация хроматическая** – Төс аберрациясе, хроматик аберрация.* Мондый аберрация сыңар линзаларга аеруча хас.

***Абсолютная высота** – Абсолют биеклек.* Җир өслегендәге теге яки бу ноктадан океанның уртача кимәленә кадәр булган ара. Геодезиядә *альтитуда* дип атала, аны *нивелир* ярдәмендә билгелиләр. Россиядә Кронштадттагы футштокның

нуль ноктасыннан башлап санала. (*Футшток* – инглизчә *фут* һәм немецча *шток (таяк)* сүзләреннән тора; океан-диңгезләрдә, елга-күлләрдә су кимәлен күзәтеп тору өчен хезмәт итә торган бүлемле рейка.)

Кара: ***Альтитуда***.

***Абсолютная болометрическая звёздная величина Солнца*** – *Кояшның абсолют болометрик йолдызча зурлыгы*. Ул $+4^m,72$ гә тигез.

***Абсолютная звёздная величина*** – *Абсолют йолдызча зурлык*. Теге яки бу яктырткыч 10 пк ераклыктан караганда ия булган йолдызча зурлыкка тигез.

***Абсолютная температура*** – *Абсолют температура*. Ул $-273,18^{\circ}$тан башлап исәпләнә. Бу температура төшенчәсе Уильям Томсон (лорд Кельвин, 1824–1907) тарафыннан кертелгән, һәм шуңа күрә абсолют температуралар шкаласын *Кельвин шкаласы* дип атыйлар. Абсолют температура берәмлеге – *Кельвин* (К).

Кельвин градусына яңа билгеләмә бирелгәннән соң, суның кайнау температурасы $100^{\circ}$ ка түгел, бәлки $99,995^{\circ}$ ка тигез булып чыга.

***Абсолютная фотовизуальная звёздная величина Солнца*** – *Кояшның абсолют фотовизуаль йолдызча зурлыгы*. Ул $+4^m$, 96 га тигез.

***Абсолютная фотографическая звёздная величина Солнца*** – *Кояшның абсолют фотографик йолдызча зурлыгы*. Ул $+5^m$, 59 га тигез.

***Абсолютно чёрное тело*** – *Абсолют кара җисем*. Нурланышны идеаль йота һәм идеаль тарата торган җисем. Чын (реаль) җисемнәр бу сыйфатларга ия түгел, ләкин теориядә, әйтик, Кояшны һәм йолдызларны абсолют кара җисем дип санаганда, барыбер билгеле бер төгәллеккә ирешелә.

***Абсолютный ноль (температуры)*** – *Абсолют нуль(гә тигез температура)*. Бу – физик җисем ия була алган иң түбән температура, ул $-273,18^{\circ}$ ка тигез, ләкин мондый температурага ирешү мөмкин түгел.

*Нуль/ноль* – латинча «һичнинди, бернинди дә түгел (русча *никакой*)» мәгънәсендәге сүз. Гомумән, нуль – теге яки бу координаталар системасында башлангыч нокта, исәп башлангычы.

***Абсцисса*** – *Абсцисса*. Өч үлчәнешле турыпочмаклы координаталар системасында *OX* күчәре, латинчадан «өзелгән, кисеп алынган» мәгънәсендәге сүз. Башка күчәрләр – *ордината* (*OY* күчәре) һәм *аппликата* (*OZ* күчәре).

***Авригиды (августовские)*** – *Авригидлар (августныкылар)*. Метеорлар агышы. Активлыгы 14–31/VIII чорына туры килә. Атамасы Йөкче йолдызлыгы исеменнән (латинча *Auriga*). 1872 елда Англиядә күзәтелгән, ләкин агышның ачылуы Германиягә нисбәт ителә (1930).

***Авригиды (февральские)*** – *Авригидлар (февральнекеләр)*. Метеорлар агышы. Активлыгы 8–12/II чорына туры килә. Атамасы Йөкче йолдызлыгы исеменнән (латинча *Auriga*). Беренче тапкыр 1877 елда Англиядә күзәткәннәр.

***Автоколлимация*** – *Автоколлимация*. Оптик коралның коллиматорыннан параллель бәйләм булып чыккан нурларның, яссы көзгедән кайтарылып, кире юнәлештә баруы. Әгәр дә көзге системаның күчәренә перпендикуляр булса, нурландыручы нокта кайтарылган нурларда аның сурәте белән тәңгәл килә; көзгене бору исә сурәтнең тайпылуына китерә. Бу күренеш, мәсәлән, спектраль җайланмаларда оптик детальнең өлекләре паралельлеген тикшерү өчен киң кулланыла.

Кара: ***Коллиматор***.

***Агена*** – *Агена*. Центавр йодызлыгының β сы (бетасы). Атаманың килеп чыгышы анык түгел. Бу йолдызның икенче исеме *Хадар* исә язылышта хәреф хатасы җибәрелү аркасында барлыкка килгән, диләр.

***Адхафера*** – *Әддафира.* Арыслан йолдызлыгының ζ сы (дзетасы). Атама гарәпчәдән, *әд-дафира* «Арысланның муены» мәгънәсендә.

***Азбука звёздного неба*** – *Йолдызлы күк әлифбасы.* Йолдызлы күк йөзе буенча юл күрсәткеч.

***Азимут астрономический*** – *Астрономик азимут.* Астрономиядә яктырткыч вертикаленең көньяк ноктасыннан почмакча ераклыгы. Азимутларны көньяк ноктасыннан сәгать йөреше уңаена (көнбатышка таба) саныйлар. Ул градуслар, минутлар һәм секундлар белән, күбесенчә 0 дән алып 360° ка кадәр үлчәнә.

Тимерказык йолдызының астрономик азимуты: 180° + 1°03′ = 181°03′.

*Азимут* сүзе гарәпчәдән (*әс-сумут* – вертикаль түгәрәк). *Зенит* сүзе дә шул нигездән.

***Азимут геодезический*** – *Геодезик азимут.* Геодезиядә азимутлар төньяк ноктасыннан көнчыгышка таба 0 дән алып 360° ка кадәр яки 0 дән алып 180° ка кадәр (көнчыгыш азимутлар) һәм 0 дән алып –180° ка кадәр (көнбатыш азимутлар) үлчәнә.

***Азимут инструмента*** – *Инструментның азимуты.* Астрономик инструмент урнашкан урынның бер координатасы – азимуты.

***Азимут истинный*** – *Чын азимут.* Бирелгән нокта урнашкан чын (географик) меридианның төньякка юнәлеше белән координаталар челтәренең вертикаль сызыгы арасындагы почмак.

***Азимут магнитный*** – *Магнитча азимут.* Геодезиядә магнит меридианы белән теге яки бу объектка юнәлеш арасындагы почмак.

***Азимутальный круг*** – *Азимут түгәрәге* (күк сферасында).

*Азимут түгәрәге* дигән прибор да бар. Ул компасларда һәм навигация җайланмаларында горизонталь яссылыктагы почмакларны үлчәү өчен хезмәт итә. 0 дән алып 360° ка кадәр бүлемнәре булган түгәрәктән яки боҗрадан гыйбарәт.

***Азимутальная установка (монтировка)*** – *Азимуталь җайланма; азимут штативы.* Телескопны вертикаль һәм горизонталь күчәрләр тирәсендә азимут һәм биеклек буенча төрлечә юнәлтергә мөмкинлек бирә торган җайланма; бу автомат механизм телескопны йолдыз артыннан үзе бора.

***Азия*** – *Азия.* 1861 елда астроном Норман Роберт Погсон (1829–1891) тарафыннан ачылган астероид, диаметры: 60 км, Кояш тирәли әйләнү периоды: 3,766 ел. Атама борынгы Ассирия телендәге *асу* (шәрык, көнчыгыш, Кояш чыгышы) сүзеннән килеп чыккан дип уйланыла. Ассириялеләр Эгей диңгезенең көнчыгыш яр буйларын *Асу* дип атаганнар.

***Акамар*** – *Акамар.* Эридан йолдызлыгының θ сы (тетасы). Атама гарәп теленнән, *ахирән-нәһр* «елганың ахыры» мәгънәсендәге сүздән. Күрәсең, борынгылар бу йолдызны күк елгасы *Эриданның* ахыры дип санаганнар.

***Аквариды*** – *Акваридлар.* Метеор агышлары комплексы, ел саен апрель азакларында – май башларында һәм июль азакларында – август башларында кабатлана. Радиантлары *Сукояр* йолдызлыгында, атамалары да шуннан (латинча *Aquarius*).

Беренче тапкыр Кытайда безнең эраның 401 нче елында күзәтелгән (η акваридлар).

***Аквилиды*** – *Аквилидлар.* Метеорлар агышы. Активлык чоры 19–23/IV/1885 елдан билгеле, Англиядә күзәтелгән. Атамасы Каракош йолдызлыгының латинча исеменнән *(Aquila)*.